ГЛАВА
Кучуковского сельского поселения
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Көчек авыл җирлеге
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2020 Түбән Көчек авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2020 елның 26 ноябрендә 12 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын 2020 елның 26 ноябрендә 14 сәг 00 мин билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Варклед-Бодья ав. Ленин, Киров, Береговая урамнарында яшәүчеләр

- 2 этап: Варклед-Бодья ав. Совет, Яшьләр, Болын урамнарында яшәүчеләр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия

Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Варклед-Бодья авылында Молодежная, Киров, Луговая урамнары юллары өчен вак таш сатып алу һәм җәю;

2. Варклед-Бодья авылы урамнарына хезмәт күрсәтү – кардан чистарту;

3. Варклед-Бодья авылында Береговая урамында суүткәргеч торбалар сатып алу һәм алыштыру;

4. Варклед-Бодья авылында су башнясын коймa белән әйләндереп алу;

5. Варклед-Бодья авылында су башнясы өчен тирәнлек насосы сатып алу.

6. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машиналарының запас өлешләрен сатып алу һәм аларны ремонтлау, янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә шартнамә буенча түләү, янгын сүндерү машинасы өчен бинаны ремонтлау);

7. Бишенче линия урнаштыру, лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны ремонтлау һәм алыштыру, Варклед-Бодья авылында урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу;

8. Варклед-Бодья авылында Бөек Ватан сугышы һәйкәлен ремонтлау;

9. Варклед-Бодья авылында аншлаг урнаштыру, йортларга, урамнарга адреслы табличкалар ясау һәм хуҗасыз йортларның коймаларын яңарту;

10 Варклед - Бодья авылында күмү җирләрен карап тоту (зират коймасын яңарту);

11. МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен өстәмә асылма җиһазлар сатып алу (төягеч, ротор чапкычы)

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Варклед-Бодья ав., Совет ур, 26Б адресы буенча урнашкан авыл клубында уздырырга.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.А.НУРМӨХӘММӘТОВ